ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 100 2022 ел, 16 февраль

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Уставына таянып, Федераль законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль-шәхси партнерлык турында» 02.06.2021 ел, № 49 карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Кушымтаның 7 бүлегендәге 8 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, утильләштерү, йогышсызландыру, урнаштыру, медицина калдыкларын җыю, куллану, зарарсызландыру, урнаштыру, саклау, ташу, исәпкә алу һәм утильләштерү гамәлгә ашырыла торган объектлар».

2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы муниципаль хезмәте вазыйфалары реестрына (Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестры турында» 30.07.2014 ел, №222 карары белән расланган) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

2.1. «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфалары» 2 нче бүлекнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары:

- мөстәкыйль бүлек башлыгы урынбасары;

- мөстәкыйль сектор мөдире.»

3. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисенә акчалата бүләкләүләр, Аксубай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен, айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында» 26.04.2018 ел, №138 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1. 2 нче кушымтаның таблица өлешенә «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын исәпләгәндә кулланыла торган нисбәт коэффициентлары» түбәндәге эчтәлекле 14 юл өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 14. | сектор мөдире | 1,47 |

4. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында яңа редакциядәге нигезләмә хакында» 24.08.2018 ел, № 158 карары белән расланган) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1. 42.3 пунктның 5 өлешендә «2019 елның 1 гыйнвары» сүзләрен «2025 елның 1 гыйнвары» сүзләренә алмаштырырга.

5. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының http://aksubayevo.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе К.К.Гыйлманов